**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылында гражданнар җыены карары**

17 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- Рус Кырык Садагы авылындагы торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, эшләр һәм договор буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?»

3. Җыен нәтиҗәләрен Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кырык Садак авыл җирлеге башлыгы _________ В.Ф.Шаһиева

Гражданнар җыены секретаре _________ Ф.Г.Миннегалиева